| ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

д. Канаш

№1 14.01.2016

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 1 статьясы, “Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында” 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2016 елның 12 гыйнварында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча үзара ярдәм итешү турында килешү нигезендә,

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турындагы белешмәләрне муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының, муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар хакындагы белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча эш барышында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү Регламентына җитәкчелек итәргә; алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының 2016 елның 11 гыйнварындагы муниципаль районы белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертергә;

2. Район Советына җирлек Советы, җирлек башлыгы һәм Башкарма комитетның муниципаль норматив хокукый актларын, шулай ук регистрка кертелергә тиешле белешмәләрне җибәрү өчен җаваплы итеп җирлек Башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

3. Карарны Югары Ослан районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы

Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков